СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2016 елның «11» февраленнән** **№ 9-30**

**«2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы, Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен Яңа Чишмә муниципаль районына «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында килешүләр нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә (бастырырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә (комиссия председателе Дворецкая С.П.).

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

**2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба – прогноз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында нигезләмә нигезендә эшләнде.

**2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек**

2016 елда түбәндәге муниципаль күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

**2016 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр**

| №т/б | Муниципаль милек исеме | Урнашкан урыны | Мәйданы, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ашханә бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Зирекле авылы, Колхоз урамы, 18 | 59,3 | 2016 елның 2 кварталы |
| 2 | Кибет бинасы һәм җир кишәрлеге | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Кызыл Октябрь совхозы, Үзәк ур., 13 й. | 166,4 | 2016 елның 3 кварталы |
| 3 | Кибет бинасы һәм җир кишәрлеге | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Кызыл Октябрь совхозы, Үзәк ур., 13а й. | 116,5 | 2016 елның 4 кварталы |
| 4 | Мунча бинасы һәм җир кишәрлеге | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Кызыл Октябрь совхозы, Спорт ур., 4 й. | 118,7 | 2016 елның 3 кварталы |
| 5 | Сарай бинасы | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Октябрь ур., 76 | 17,7 | 2016 елның 3 кварталы |
| 6 | Гараж бинасы, | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акбүре авылы, Совет ур., 40 й. | 40,0 | 2016 елның 4 кварталы |